Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 13**

Зур Мәшләк авылы 2023 елның 25 декабре

**2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешнең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12 һәм 14-15 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсендәге 8 өлешнең 2 пункты, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Уставының 19 маддәсендәге 2 өлешнең 3 пункты һәм 70,71 маддәләре нигезендә ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ**:

**1 маддә**.

1. 2024 елга ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 3527,66 мең сум итеп;

2) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 3527,66 мең сум итеп;

3) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 0,0 мең сум итеп.

2. 2025 елга һәм 2026 елга ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2025 елга 3608,65 мең сум, 2026 елга 3748,25 мең сум итеп;

2) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2025 елга 3608,65 мең сум итеп, шул исәптән 86,02 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар, 2026 елга 3748,25 мең сум итеп, шул исәптән 178,22 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар;

3) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 2025 елга 0,0 мең сум, 2026 елга 0,0 мең сум итеп.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 маддә.**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2025 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2026 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2027 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

**3 маддә.**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджетында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмен 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 маддә.**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджетының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджетының 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын раслау турында " 4 нче кушымта нигезендә.

**5 маддә.**

**1.**Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә алына торган дотацияләр күләмен 2024 елга 2307,75 мең сум күләмендә, 2025 елга 2355,79 мең сум күләмендә, 2026 елга 2464,72 мең сум күләмендә расларга.

**6 маддә.**

1. 2024 елга Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан 152,46 мең сум күләмендә, 2025 елга 167,85 мең сум күләмендә, 2026 елга 183,95 мең сум күләмендә Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга

7 **маддә.**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2024 елда һәм 2025, 2026 еллар план чорына муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләре, шулай ук аларны карап тоту чыгымнары артуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**8 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар

**9 маддә.**

1.Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә 2024 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге бюджеты акчаларының калган өлеше 2023 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча төзелгән, 2024 елда Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**10 маддә.**

1. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**11 маддә.**

1. Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13а йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариман урамы, 24А йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшлэк авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Заһидуллин

СОВЕТ БОЛЬШЕМАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ